# БЕРГЕНӘМ - БЕРДӘНБЕРЕМ




*Ике зат - киселгән алма кебек. Аларның һәркайсы үз яртысын эзли. Ләкин, кызганычка, бу ике ярты алма беркайчан да тулысынча тәңгәл килә алмый.*
***Заһид МӘХМҮДИ.***

**Гыйбрәтле мәхәббәт тарихлары, кеше язмышлары, хуҗабикәләргә киңәшләр, тегү-чигү, йолдызнамәләр, күрәзә, медицина яңалыклары.**

№ 2 (68)
Февраль
2023

Айга бер тапкыр чыга

Индексы П 5250
Ярты елга язылу бәясе 171 сум



## Гомер буе кешедән качып очраштык

***Мине бер сорау борчый. Бәлки сез бу сорауга җавап бирерсез. Әйтегез әле, ярату — гөнаһмы ул? Кешегә гашыйк булып, аны ратып яшәү начар гамәлме?***

***Ләйсән белән бергә үстек, бер сыйныфта укыдык. Әниләр дә дуслар булып аралашып яшәде. Ләйсәннең бездән ике яшькә кечерәк бертуган энесе бар. Исемен Ленар дип әйтик. Кайвакыт ул да безнең белән урамга чыга, клубларга йөри иде...***

(15 нче бит)

## «Мин бала таба алмыйм»

***Поезд һава дулкынын ярып алга чаба. Урыннарга урнашу ыгы-зыгысы тәмамланганнан соң, пассажирлар, гадәттә, тамак ялгый-ялгый, хатирәләргә чума. Бер-берсен гомердә күрмәгән кешеләр күңел серләрен ачыктан-ачык бушатырга керешә.***

***— Яшь чакта бик чибәр идем, - дип башлады үзенең кыйссасын Тәнзилә ханым. - Йөргән егетләрем дә булды. Таһир белән ратышкан идек, аны армиягә дә озатып калдым...***

(3 нче бит)



podpiska.pochta.ru

# “Туганда ук бәхетсез булып туганмын”

Нәсимә күрше авылга килен булып төшүгә, каенанасы Тәския белән бер йортта яши башлый. Каенана аңа булышу йөзеннәнме, әллә үзенең хуҗа икәнен күрсәтү максатыннанмы, аш-суны үзе әзерли торган була.

Беренче балалары тугач, аңа исемне дә Мәдинә, дип куштыра. Шуннан соң да, бер-бер артлы дөньяга килгән балаларны авырсынмый тәрбияләргә булыша ул. Үзе яшьтән иреннән калып, өч баласын ялгызы үстергән. 100 яшенә җитеп вафат була Тәския әби. Авылда йорт саен күп бала була ул чакта. Нәсимә белән Халит та ишле гаилә турында хыяллана.

Олы кызлары — Мәдинә мәктәпне тәмамлауга, иптәш кызлары белән шәһәргә китеп бара. Хисапчы булырга хыяллана ул. Авылга кайткач, әнисенең бишенче бала алып кайтырга җыенуын белүгә, аңа үзенең үпкәсен дә белдерә. Табиблар кисәтүенә карамастан, аларны тыңламавы борчый аны. Ә инде бәби алып кайтыр вакыты җиткәндә, күңелсез төшләр дә күрә Мәдинә. Көн саен әнисе турында хәбәр көтеп йөри.


Беркөнне ул дәрестә чагында, тулай торакка телеграмма китерәләр. “Тизрәк кайт, әниең авыр хәлдә”, — дип язылган була анда. Ул көнне дәрескә соңрак барырга булган Гөлсия тизрәк техникумга чыгып йөгерә. Телеграмманы Мәдинәгә тапшырганнан соң, үзе дә аның белән кайтырга җыенуын укытучысына әйтә. Алар юлга чыкканда, көн кичкә авыша. Көч-хәл белән районга кайтып җитәләр. Тагын 40 чакрым кайтырга машина көтәргә кирәк. Юл буе: “Әни исән генә була күрсен иде”, — дип кабатлый-кабатлый кайта Мәдинә. Әмма ул теләгәнчә булмый шул.

Өйләренә кайтып керсәләр, өстенә ак җәймә капланган әнисенең гәүдәсен күреп, кыз аңын җуя. 41 яшендәге әниләренең бала тапканда, үзләрен ятим калдырып якты дөньядан китеп барыр, дип кем уйлаган соң?! Җитмәсә төпчек сенелләренә биш яшь тулган көн була бу. Туачак сабыена әниләре Зөһрә, дип кушарга хыялланган була. Шуны истә тотып, кызга әнә шул исемне куйдыралар.

Сабыйны бала тудыру йортыннан Казанга — приютка алып китәләр. Өйдә калган балалар һәркөнне әниләрен юксынып, күз яшьләрен түгә. Бераздан Халитны авылда ялгыз яшәүче Нурсөягә димлиләр. Ул гаиләгә килү белән, баланы алып кайтып, өч яшенә кадәр үстерергә булыша. Әмма ни сәбәпледер, Халит белән Нурсөя аерылыша.

Бәләкәй Зөһрә әбисе белән 15 яшьлек апалары Илзия кулына кала. Ул үсә төшкәч, апалары мәктәпне тәмамлап авылдан китеп бара. Шул чактан бирле өйдәге бөтен эш аның җилкәсенә төшә.

Мәдинә апалары кияүгә чыгып, ике бала үстерә. 41 яшенә җиткәндә: “Минем яшьтә әни безне ташлап китте”, — дип балаларына да сөйли ул. Шуннан соң, озак та үтми, Мәдинә эче авыртудан зарланып



табибка бара. Хастаханәдә ятуның да шифасы тими. Республика клиник хастаханәсенә китергәннән соң, бер-бер артлы ике операция кичерә Мәдинә. Әмма соңгысында наркоздан айнымый. Нәкъ әнисе яшендә гүр иясе була.

Калган апаларының да гаилә бәхете булмый. Зөһрә укуын тәмамлауга, сатучы булып эшли башлый. Шәһәрдән гаиләләре белән авылга күченеп кайткан егет үзенә гашыйк була. Әти-әниләре рөхсәте белән чәчләре чәчкә бәйләнә аларның. Әмма тора-бара ир хәмер белән мавыга. Зөһрә ике баласын аякка бастырганчы түзә. “Туганда ук бәхетсез булып туганмын бит мин. Бер бәхетең булмагач, юк инде”, — ди ул.


Ире Сәет акча эшләү максатыннан, башка шәһәргә китеп бара. Башта берничә айга бер, аннан озаккарак сузыла аның кайтып йөрүләре. Бервакыт Сәет кайта да, ике улы белән Зөһрәгә: “Сез әтиегезне башка көтмәгез инде, безнең кызыбыз туды. Бөтенләйгә шулар янына китеп барам”, — ди. Бу сүзләргә ир балалар да, хатыны да өнсез кала. Икенче көнне әтиләре башка гаиләгә китеп бара.

Алар әниләрен авылда ялгыз гына калдырмый. Үзләре белән шәһәргә алып китеп, аны эшкә урнаштыралар. Тормышның ачысын татып үскән Зөһрәнең үзенә таяныч булырдай шундый уллары булуы авылдашларын да сөендерә.

Әтиләре кайчан да булса балалары ярдәменә мохтаҗ булмасмы? Анысы әлегә билгесез.

**Люция ХӘБИБУЛЛИНА.** “ШК”.

podpiska.pochta.ru



# «Мин бала таба алмыйм»

Поезд һава дулкынын ярып алга чаба. Урыннарга урнашу ыгы-зыгысы тәмамланганнан соң, пассажирлар, гадәттә, тамак ялгый-ялгый, хатирәләргә чума. Бер-берсен гомердә күрмәгән кешеләр күңел серләрен ачыктан-ачык бушатырга керешә.

— Яшь чакта бик чибәр идем, - дип башлады үзенең кыйссасын Тәнзилә ханым. - Йөргән егетләрем дә булды. Таһир белән яратышкан идек, аны армиягә дә озатып калдым. Ләкин яшьлек юләрлеге галәмәте: Александрга гашыйк булып, кияүгә чыктым. Ул болай начар кеше түгел, тик үтә дә көнче, исерсә дуамал. Берәрсенә кунакка барсак, үзе: «Бие-бие, миңа карап торма», - дип рөхсәт бирә. Ә инде өйгә кайтуга: «Син теге ир-ат белән биедең, бу ир-ат белән сөйләштең», - дип кыйный башлый иде. Котырынган исерек ирне кая җиңәсең? Куркудан елап басып торучы улым Олегны күтәреп, кар өстеннән яланаяк күршеләргә чыгып йөгергән вакытлар шактый булды. Александр, айныгач, күз яшьләрен түгеп, гафу үтенә, тагын дуслашабыз. Соңгысында ул мине эчемә тибә-тибә кыйнады. Эчемнең авыртуы басылмагач, хастаханәгә яттым. Аналыгымны изгән икән, мөртәт. Операция ясатканнан соң, баламны алып, Александрдан аерылдым.

Тәнзилә ханым әле генә операция өстәленнән төшкән сыман авыр сулап куйды.

— Кабат кияүгә бару турында уйламадым да, ир-атка карата бәгырем каткан иде, - дип сөйләвен дәвам итте сәфәрдәш хатын. - Берничә ел үткәч, очраклы гына яшьлек мәхәббәтем Таһир белән очраштык, ул да өйләнгән иде инде. «Эх, Тәнзилә, мин яраткан идем бит сине!» - диде.

Шулай бервакыт оешмабызга 42 яшьлек Марат атлы ир эшкә урнашты. Танышып, үзеннән-үзе дуслашып киттек. Миңа 35 яшь иде, үзенә кияүгә чыгуымны сорады. Теләгем дә кузгалды кузгалуын, тик шикләндерә дә. «Мин бала таба алмыйм бит», - дип тә карадым. «Бер-беребезгә иптәш булып яшик, балаларыбыз бар бит инде», - дигәч, ризалаштым. Марат беренче хатыны белән шулай ук аерылышкан икән, аннан кызы бар. Икенче бер хатын белән очрашкалап йөргән, анысында улы үсә.

Тырыш, шулкадәр кайгыртучан Маратым. Бер-беребезне сагынышып, яратышып яшибез. Йорт җиткездек, машиналар сатып алдык. Олегны да үз баласыдай якын күрде. Маратның улы белән кызы да безгә кунакка килеп йөриләр. Тормышыбыз мул. Хәзерге иремнең дә балалары «әни» дип дәшәләр. Ничектер кызык та, шул ук вакытта рәхәт, күңелле дә.

Чит илләргә ял итәргә барганда Маратның да йә улын, йә кызын үзебез белән алабыз. Беренче хатынын да онытып бетермәскә кушам. Үзем чәчәк алып кайтып: «Бар, котлап кайт», - дим. Нәрсә-нәрсә, чәчәк сатып алмый инде ул. Шулай кулына тоттыргач, барып, котлап кайта.

Тәнзилә ханым, йөзеннән нур чәчеп, матур гына көлеп куйды.

— Аллага шөкер, бүгенге тормышымда бәхетлемен. Балалар да тәртипле булып үстеләр. Әмма ике генә үкенечем бар. Бүгенге акылым булса, исерек ирдән кыйналып-сугылып бер көн дә яшәмәгән булыр идем. Ул еллар куркыныч төш кебек. Язмышыма әлеге афәтләрне дә кичерергә язылган булгандыр, күрәсең. Икенче үкенечем: хәзерге ирем белән уртак балабыз юк. Акылым, җаным-тәнем белән яраткан Маратымнан шулкадәр дә бала табасым килде. Кызганыч, мин бала таба алмыйм, - дип тәмамлады сүзен юлдашыбыз.

«Сәйдәш» маршы авазлары астында поезд вокзалга кереп туктады. Тәнзилә ханымны да ире һәм балалары йөгерешеп килеп, кочаклап алдылар. Бәхетләренә күз тимәсен, бу дөньяда яратышып, дус-тату яшәүгә ни җитә?!

"ШК".

podpiska.pochta.ru

# Кияүгә чыкканнан бирле рәхәтләнеп ашаганым да юк - гел диетада



Җәйге ялыбыз вакытында кызык пар белән танышкан идек. Башларында мөгез үсмәгән үсүен - бары тик хатыны иреннән унөч яшькә зур. Ун яшьлек уллары бар үзләренең. Кызыгы исә кырыкны узган хатынның бала булып күренергә тырышуында. Кызганычы - ул иренең саруын соң дәрәҗәгә җиткереп кайната иде...

Пар тек пар инде, дип башта игътибар да итмәдек. Әмма бераздан күз үзеннән-үзе аларга төшә башлады. Курганнан килгән әлеге ир белән хатын икесе ике полюс белән бер. Хатын мунча миллеге яфрагы кебек иренә ябышып диярлек йөри, бертуктаусыз нидер сөйли, тегесе исә үз чиратында, чирканган кыяфәт чыгарып, теш арасыннан сөзеп кенә җавап бирә. Үзенең күзендә кешеләрдән кыенсыну димме, оялумы - әмма хатыны белән аралашу аның өчен җан газабы икәне йөзенә язылган. Башта хатынкайдан ял иткән һәр кеше диярлек көлде бугай - арттан пионер, алдан - пенсионер дигән уй кемнең генә башына килмәде икән?

Инде яшьлек матурлыгы шактый артта калган хатынкайның яшьләрне, мәктәп балаларын уздырып кып-кыска күлмәк-шортылар киюе, йөзенә балалык гөнаһсызлыгы ягарга тырышып йөрүе ирен читенә елмаю кундыра иде. Шактый юкарган чәчен баш түбәсенә койрык итеп җыеп куя да ике зур колагы тырпаеп кала... Һәр яшьнең үз кысалары шул. Матур тыгыз тән булмаса, аны инде күрсәтүдән күрсәтмәвең артык дигәндәй. Ир, бахыр, шуны аңлапмы, «Ник тагын бу күлмәгеңне киден, үзеңне көзгедән күрдеңме?» - дип, үртәлүен күрсәтеп тә тора. Соңрак билгеле булганча, иргә әле күптән түгел генә утыз тулган икән, хатынкай - Оксанага яңа ел төнендә 44 туласы.

- Утыз яшемә якынлашып та кияүгә чыга алмый тилмердем, - дип Оксана язмышын көтмәгәндә бәян итте. - Әлбәттә инде, моны мин ир күрмәгән кеше, дип аңларга кирәкми. Ул яктан күңелне күрүчеләр табыла иде, аннан, син яхшы, дип ашыга-кабалана хатыннары янына чабалар иде. Мендәргә елап туйдым, ялгызы гына мине үстергән әнием, язмышың шулдыр, кун, дип нервыга тия җитмәсә. Ник күнim ди мин? Үземнең яшьтәгеләрдән өмет өзгәч, максат куйдым - берәр яшьрәкне табам да, булган тәҗрибәм белән башын әйләндереп, өйләндерәм. Васяны мин күреп, әһә, бу миңа кирәкле кеше дигәндә, аңа унҗиде яшь иде. Әни, кеше баласын әрәм итмә, барыбер бергә торып бетерә алмыйсыз, диде. Кеше язмышын кайгыртканчы, минем әле үз язмышым бар! Мин моның белән аралаша башладым. Маңка гына малай булса да, һаман башка ир-атлар кебек кулланмакчы гына була мине. Юк, дидем, бу юлы алай итә алмассың.

Бергә булганда бар назымны бирәм дә моңа, бер-ике айга югалып торам - телефонны алмыйм, очрашуга бармыйм. Тилмерә бу балакай. Шулай өч-дүрт тапкыр булгач, моңа әйтәм: «Безнең балабыз була, ахры, аборт ясатырга булыш әле». Ә бу үзе дә бала бит - калтырап төште. Бала үтерттерә алмыйм, бергә яшәп карыйк ише җөмләләр төзи. Мин моңа: «Синең язмышыңны ботарлый алмыйм, әниләрең мине мәңге кабул итмәячәк», - дип лирика тезәм. Өйрәтеп куйганнар иде - ир кешене әлеге алым «ала». Алды - әниләре янына, теләсәгез-теләмәсәгез өйләнәм, дип алып барды. Әнисе акаеп карады инде, ә миңа аның әнисе ни, әбисе ни... Ир булсын! Булды! Шөкер, корсакка уза алмый интекмәдем - тиз уздым. Бер ел дигәндә, малай туды.

- Ирең белән яшәүләре артык җайлы түгел кебек күренә, - диюгә исә:

- Булса соң, - ди Оксана. - Аның сытык чыраеннан укам коелмый минем. Иң мөһиме - ул минем ир. Безнең бала бар. Ә мин хәзер бала-чага түгел инде - ирне ничек тотарга икәнен бик яхшы беләм. Малайны да шул ук эшкә җигәм. Күрми күргән ир ул, болай гына аерылышу да, башка хатынга китү дә булмаячак.

"ШК".

podpiska.pochta.ru

# Бала язмышы: көн дә исерек әнисен өенә сөйрәп кайта



Беркөнне урамда утырам. Күк йөзе яңгыр болытларыннан караңгыланып торса да, тышта барыбер рәхәт – саф һава, талгын җилдә куышлы уйнап йөрүче сары, кызыл «шаян» яфраклар, көз исе. Кинәт, урам тынычлыгын бозып, күрше тавыгы, һөҗүмгә җыенгандай, яңгыратып аваз салды.

Борылып караган идем, ала карганы куып маташа. Моның шулай тынычсызлануының сәбәбе нидә икән дип уйлыйм: тавыкларның тик торганда каргаларга ташлана торган гадәте дә юк төсле, чебешләрен яклыйдыр дисәң, кышка кергәндә, нинди чебиләр булсын ди инде?! Ә юк, дөрестән дә, ана инстинкты икән, әнә, балалары төрле почмаклардан йөгерешеп чыгып, әниләренә сыеныштылар.

Тик боларны инде чебешләр дип әйтеп булмый, өчесе дә буйга әниләрен куып җитеп киләләр. Ул-кызлары әни кеше өчен ничә яшьтә дә бала булып кала, диләр, күрәсең, бу канун тереклекнең түбән төрләре өчен дә хас икән, дигән карарга киләм.

Шулчак Казан шәһәрендә булган бер вакыйга хәтергә килә. Кышкы кич, салкын, буран дулый. Дустым белән тукталышка чыгып барабыз. Кинәт, тукталыштан читтәрәк, сәләмә генә киенгән, әллә суыктан, әллә башка сәбәп аркасында, елап торучы кечкенә кызчык күзгә чалына. Якынрак килгән идек, кызый: «Дяденьки, дяденьки, помогите поднять мою маму!» – дип, күз яшьләре белән ялвара башлады.

Тукталыш мәйданчыгы артында кызның аягында басып тора алмаслык дәрәҗәдә исерек әнисе аунап ята икән. Дустым белән моны күтәреп бастырдык бастыруын, тик исерек аяклар исерек гәүдәне тотмый иде шул. Кызы сорагач, лыкынганчы эчкән хатынның авызыннан чыккан сүгенү катыш янау сүзләрен тынлый-тынлый, култыклап өенә кадәр озатып куйдык. Кызчык: «Спасибо большое, дальше я сама», – дип артыбыздан фатир ишеген ябып калгач, юлыбызны дәвам иттек. Автобуста уйларыбызга батып, сүзсез кайттык, ул вакытта икебезнең дә башында бер чамарак фикерләр булгандыр инде.

Әлеге хәлне искә төшергәч, шуңа әле яңа күзаллаган вакыйганы да бәйләп, икесен бергә анализлап утырам. Берсенең герое – зиһенсез, аңгыра саналучы тавык, икенчесенеке – акылның иң бөек ноктасына ия булучы зат – кеше. Икесе дә – әни. Тик башсыз тавык үзенең инде күптән мөстәкыйль яши башларга тиешле балаларын һаман да кайгырта, ә кеше өчен газиз кызчыгы бар ни, юк ни, аңа аракы гына булсын. Кызның: «Дальше я сама», – дигән сүзләреннән, әнисенең шундый хәлдә бик еш булгалавы аңлашыла. Ул яшендә әнисе кочагында назланып, иркәләнеп тәрбияләнергә, көндәлек проблемалардан олылар аркасы артына яшеренеп, кайгы-хәсрәт, мәшәкатьләрне белмичә яшәргә тиешле мескен кызчык балачактан кырыс чынбарлыкны татып үсә. Бер генә сорау туа: башка тереклек ияләре арасында иң өстене, зиһенлесе булып яратылган кеше торган саен акыллар баскычы буенча аска тәгәри түгелме?!

**Айнур ГАЛИМОВ,**
"ПК".

## "САЛАВАТ КҮПЕРЕ" САЛАТЫ

РЕЦЕПТ



*Чи кишер, пешкән чөгендер, пешкән ит (колбаса, ысланган тавык түше дә ярый), пекин кәбестәсе, кыздырган бәрәңге, майонез.*

*Барлык ингредиентларны бертигез күләмдә алырга, саламлап турарга яки махсус кыргычтан чыгарырга. Бәрәңгене кыздырырга һәм, маен саркыту өчен, дуршлагка салып торырга, салфетка белән корытырга. Яссы тәлинкәгә өеп куярга. Салатны табынга чыгаргач кына болгатырга.*

podpiska.pochta.ru

# Күрәзәче әби: "Башта гөнаһ эшлисез, аннары дәва эзлисез" дип ачуланды...



Күктә кояш елмая. Агачларда кошлар сайрый, тирә-юньнән хуш ис бөркелә. Җәйге урман нинди матур була икән ул! Алия шул матурлыкны күреп, уйга батты. Бу аның тормышында иң бәхетле мизгелләр иде. Тирә-юньдәге матурлыкта ул үз тормышының чагылышын күрде. Мин дөньяда иң бәхетле кеше, дип уйлап, сөенеп куйды.

Уйга баткан Алияне нәни кызчыгы Алсу кулыннан килеп тотты. "Әни!" — дип ул аны барлык уйларыннан аерып алды. Бу аларның яңа йортка күченүләренең беренче көне иде. Яратканы Фәнисне урман хуҗасы итеп билгеләгәч, шушы йортка күченеп килделәр. Туган авылыннан еракта булса да, Алия бер дә борчылмады. Чөнки аның сөйгәне — Фәнисе янында иде. Ул аның белән дөньяның аргы ягына барырга да риза иде. Ә мондагы табигатьнең матурлыгын күреп ул шаккатты. Алия үзен әкияттәге кебек хис итте. Ләкин бу әкиятнең башы гына күңелле иде шул.

Алар тирә-юньне бергәләшеп тәртипкә китерде. Чират матур итеп төзелгән өйгә җитте. Фәнис кечкенә Алсуны тотып, урман белән таныштырам дип, күл буена алып китте. Алия тиз генә өй җыештырырга кереште. Беренче ул аш бүлмәсен тәртипкә китерде һәм чәй әзерләргә булды. Барысы да әзер булгач, алдагы яктагы зур бүлмәгә күз салды. Фәнисе белән Алсуы әле кайтмаган иде. Алар кайтканчы дип, тиз генә алгы якны җыештырып алырга уйлады.

Бүлмәгә килеп керү белән, күзе почмакка төште. Анда икона эленгән иде. Аны күрүгә, Алия туктап калды. Бераз уйланып торганнан соң, аны әкрен генә алды да, алдан әзерләп куелган чүп капчыгына салып та куйды. Нәни кызчыгы белән Фәнисе кайтканчы бүлмәне җыештырып та чыгарды. Ә чүп капчыгын урман буендагы зур чокырга илтеп ташлады.

Алар шулай итеп сихри дөньяда яши башлады. Көн артыннан көн үтте. Тормышлары гөрләп торды. Икенче балалары Нияз дөньяга аваз салды. Алия үзен тормышның түбәсендә итеп хис итте. Фәнисе дә бик уңган, ярдәмчел иде. Эштән соң кайтуына да карамастан, Алиягә һәрвакыт ярдәм итә иде. Дөньябыз түгәрәкләнде дигәндә генә, тормышларының яме китеп барды.

Алия авыруга сабышты. Ул көннән-көн ябыга барды һәм аякта йөри алмаслык хәлгә килде. Фәнис аны тирә-яктагы барлык табибларга да күрсәтте. Казан шәһәрендә дә төгәл диагноз куя алмагач, алар бөтен өметләрен дә җуйды. Бер җирдә дә файда күрмәгәч, Фәнис Алияне күрәзәчегә алып барырга булды. Үзе багучыларга ышанмаса да, аңа тормышта бүтән юл калмаган иде.

Алиянең үзенең дә йөрәге ут эчендә яна. Ул төннәр буе йоклый алмыйча елап утыра. Ә шулай да сөйгән иренә дә, газиз балаларына да моңсу йөзен күрсәтмәскә тырыша иде. Фәнисе күрәзәчегә барабыз дигәч тә, аңа каршы килмәде. Күңеле белән бернигә ышанмаса да, сөйгәненең сүзен тыңларга булды.

Шимбә көне иртән Фәнис Алияне машинага чыгарып утыртты да, еракта урман эчендә урнашкан күрәзәче яшәгән авылга алып китте. Күрәзәче әби аларны ачуланып кына каршы алды. "Иртә таңнан ни эшләп йөрисез?" — дигән булды. Дулкынлануыннан Алиянең тыннары кысыла язды. Ачулы тавыш белән: "Башта гөнаһ эшлисез, аннары дәва эзлисез", — дип өстәде карчык. Алия куркуыннан берни дә эшләргә белмәде. Секунд эчендә аның күз алдыннан бөтен гомере тәгәрәп үткән төсле булды. Ләкин ул бернинди гөнаһын да исенә төшерә алмады.

Алиянең күк йөзе төсле зәп-зәңгәр күзләрен сагыш баскан иде. Аның сулып калган моңсу йөзеннән үзе дә сизмәстән яшь тамчылары тәгәрәде. Алар Фәниснең кулына төшеп, аның йөрәгенә кайнар ук булып кадалды. Карчык аларга карап торды да алгы якка үтәргә кушты. Фәнис Алияне очыртып кына түрдәге урындыкка кертеп утыртты. Алар карчыкка сүз әйтергә дә куркып тынып калдылар.

— Кызым, син зур гөнаһ эшләгәнсең, — диде күрәзәче карчык, Алиянең күзләренә карап. — Нинди гөнаһ эшләгәнеңне син исенә төшерергә һәм бер саваплы эш нәзер итеп, шуны башкарып чыгарга тиеш. Шуларны җиренә җиткереп



podpiska.pochta.ru

эшләп чыга алсаң, саулыгың кире кайтыр, — диде карчык, коры гына.

Алиянең моңсу йөзеннән бер-бер артлы күз яшьләре тәгәрәде. Ул нәрсәне исенә төшерергә икәнлеген үзе дә белми иде.

— Гөнаһ эшләгәненә бик күп вакыт үткән. Изгеләрне ачуландыргансың. Тәүбә итмәгәнсең, шуңа күрә авыруга сабышкансың. Сәламәтлегең үз кулыңда. Миннән сиңа файда юк, — дип күрәзәче карчык сүзен тәмамлады.

Карчыкның бу сүзләре Алиянең өстенә салкын су койгандай тәэсир итте. Бер секунд эчендә аның күз алдыннан урманга яңа өйгә күченгән көннәре үтеп китте. Күз алдына почмакта эленгән икона килеп басты. Алия нинди гөнаһ эшләгәнен хәзер генә аңлады.

Сөйгәне Фәнис берни дә аңламыйча, күрәзәче карчыкка рәхмәт әйтеп, Алиясен күтәреп чыгып китте. Бу Фәниснең соңгы ышанычы, өмете иде. Бер секунд эчендә бар ышанычы, өмете юкка чыкты. Бу минутларда Фәниснең йөрәге сыкрый, җаны елый иде.

Ул үзенең борчылуын Алиягә күрсәтмәскә тырышты. Тик нигәдер Алиясенең зур, зәңгәр күзләрендә өмет чаткылары кабынган иде. Фәнис аның сулып калган моңсу йөзендә елмаю күреп шаккатты. Ул ни әйтергә дә белмәде. Куркып калды. Алиянең шундый вакытта да көчле булып кала алуына исе китте. Үзен сөйгәненә ярдәм итә алмаслык көчсез кеше иттереп хис итте.

Юлда кайтканда Алия урман эчендәге аланлыкка туктарга кушты. Фәнис моңсу гына ризалашып башын кагып куйды. Ул хатынын ничек юатырга, аның күңелен тынычландырыр өчен нинди сүзләр әйтергә дә белми иде. Алиясен элеккеге хәленә кайтару өчен бүгенгә кадәр ул таулар күчерергә дә әзер иде. Ләкин күрәзәче сүзләреннән соң, ул ничектер куркып, каушап калды. Аны билгесезлек биләп алды.

Аланлыкка туктагач, ул Фәнисенә гөнаһы нидә булуын сөйләп бирде. Шушы кыска гына вакыт эчендә Алия үзен бик күпкә олыгайган иттереп хис итте. Үзенең киләчәген ачык иттереп күз алдына китерә ала иде инде.

Тормышындагы төп карарны Алия шушы берничә минут эчендә кабул итте. Бүгеннән башлап дин юлына басачагын һәм әкренләп намаз укырга өйрәнәчәген, аягы атлый башлагач, мәчеткә дин дәресләренә йөрергә җыенуы турында Фәнисенә әйтте. Моннан тыш иренә тагын бер бала алып кайтырга вәгъдә итте. Шушы минутта ул үзенең яңадан аякка басачагына бөтен барлыгы белән ышанды. Фәнисенә дә ышанычын югалтмаска кушты.

Үзенең үҗәтлеге белән Алия намазны бик тиз өйрәнде. Онлайн мәдрәсәдә белем алды. Башта намазны утырган килеш укый иде. Авырлыкларга бирешмәде. Аллаһыдан ярдәм сорады. Аллаһы Тәгалә аны ярдәменнән ташламады.

Ярты ел дигәндә Алия инде йөгереп йөри иде. Барча туганнарны, таныш-белешләрне җыеп корбан бәйрәме үткәрделәр. Алиянең бу вакытта бары тик бер хыялы бар иде. Ул Аллаһтан үзенә һәм туачак сабыена саулык бирүен сорады. Ходай рәхмәте белән аларның тормышлары яңадан түгәрәкләнде.

**Айшанур.**

РЕЦЕПТ



## БАВЫРСАК ПЕШЕРҮ ЫСУЛЫ

Бавырсак пешерү өчен бары тик авыл йомыркасын гына файдаланам. Алар тундыргычта бер ай торса, бик шәп була. Йомыркалар тундыргычта, ким дигәндә, ике атна торырга тиеш. Туң йомырка сулана, камырга яхшы була. Эш башлауның алдагы көнендә кич белән аларны тундыргычтан алып куям.


Камыр басу. Сигез йомыркадан камыр басар өчен бер чеметем тоз, бер аш калагы көнбагыш мае, ярты чәй калагы сода салына. Соданы арттырырга кирәкми, күп булса, бавырсаклар кабармый. Шуннан соң берничә кат иләнгән онны аз-азлап салып, агач кашык белән туглый-туглый камыр изелә. Аны бик озак, бер сәгать тирәсе, ялтыраганчы тугларга кирәк. Бавырсакның бөтен сере — шушы камырны бер төерен дә калдырмый озак итеп басуда. Камыр озак тугланса, бавырсак йомшак килеп чыга. Ул коймак камырыннан куерак, токмачныкыннан йомшаграк булырга тиеш.

Кисү. Камыр әзер булгач, аны күз белән якынча чамалап, өч өлешкә бүләсең. Һәм бер өлешен аерып алып, онлы тактада әвәли-әвәли озынча «тасма» («бау») сузасың. Шуларны 4—5 см озынлыкта кыек итеп кисәсең. Аларның кискән берен газ плитәсендәге майга (1 литр көнбагыш маена — 50—100 г туң май) салып барырга кирәк. Нәзек кенә тасмалар 2—3 тапкыр зуррак булып күперә. Шуңа күрә камыр кисәкләрен табакка берьюлы күп итеп салырга кирәкми, юкса алар савытка сыймый башлый.

Сироп: Пешкән бавырсаклар сироп белән балландырыла. Ул исә ярты литр суга ике стакан шикәр комы кушып әзерләнә. Кайнап чыккач, ике аш калагы бал салына.

podpiska.pochta.ru

# Тылсымлы сүз!



Сәйдә абыстай Аппакова үзенең бер сабагында «Ирләр мәшәкать яратмый», — дигән иде. «Әйтәсе сүзегезне дөрес итеп, җайлап-майлап әйтегез», — дигәнрәк мәгънәдәге киңәшен мин дә «мыегыма чорнап» куйдым.

Абыстай хак әйтә, артык мәшәкатьтән ирләрнең коты алына. Хәер, мәшәкатьне кем яратсын инде? Ләкин безнең бер аермабыз бар: хатын-кыз мәшәкатькә мәшәкать итеп түгел, ә кирәкле эш итеп, ирләр исә «шул гына хаҗәт иде» дип карый. Аларча, кибеткә бару, кирәк-ярак сайлау, яңа пәрдәләр алыштыру, ремонт ясау — барысы да — «хаҗәте бар!» Юк, яратуын алар да матур, уңайлы йортта яшәүне, тәрәзәдә күзне иркәли торган матур пәрдәләр эленеп торганны ярата, ләкин моның өчен аларны гына мәшәкатьләмәсеннәр. Аларча фикер йөртсәң, өйдәге ремонт та үзеннән-үзе ясалырга, кирәкле кием-салым да шкафка үзе кайтып утырырга, яңа пәрдәләр дә үзләре менеп басарга тиеш булып чыга.

Бәлки моны укыгач, кайбер ирләр үпкәләр, без андый түгел, дияр. Килешәм, барысы да түгелдер.

Ял көннәрендә кибеткә бергәләп чыгып, бергәләп әйбер сайлыйсы килә бит ул. Алмасаң да, бер карап кайтсаң гына да күңел булып куя. Аннары кайда нинди бәяләр икәнен белеп тору да яхшы нәрсә инде ул.

Берәр кибеткә барырга кирәк булса, менә башлана бездә бәхәс. Мин: «Әйдә инде, барып кына кайтыйк», — дип ялынам. Иремнең барасы килми: «Мине борчыма, үзең генә барып кайт инде», — ди. Баруын мин үзем генә дә бара алам анысы... Ләкин икәү барыбер дә күңеллерәк бит. Аннары, берәр нәрсә сайлаганда икәү булсаң, күпкә яхшырак. Әйтик, син үзеңә ошаган күлмәкне алып «примерочная»га кереп киттең, ди. Ә аның размеры туры килми. Кабаттан киенеп, залдан үз размерыңны табып, кабат чират торып «примерочная»га кергәнче күпме вакыт уза. Шунда янында бер кешең булса, ул гына алып килә дә бирә.

Без элек бу уңайдан бәхәсләшеп кенә калмыйбыз, бер-беребезгә үпкәләшеп туктый идек. Бик аңлыйм иремнең кибеткә барасы килмәгәнен, минеке дә килми ул. Ләкин кирәге кирәк бит аның... Кемгәдер бүләк аласы була, балаларга кием-салымы кирәк, ашарга-эчәргә, кер порошогы-сабыны... Барысын да күтәреп кайтуы да бер кешегә генә бик җиңел түгел.

Үзем дә рульгә утыргач, хәлләр бөтенләй кискенләште. Элек, машинам югында: «Үзем генә ничек күтәреп кайтыйм?» — ди идем. Хәзер моны сәбәп итеп булмый, күтәрмә, машинаңа салып кайт, дип кенә җавап бирә башлады.

Бу элегрәк, мин әле яшьрәк һәм тәҗрибәсезрәк чакта шулай иде. Ә хәзер... Хәзер мин бер тылсымлы сүз беләм. Шул тылсымлы сүз әллә нинди киребеткән ирләрне дә диваннан кузгата алырдай кодрәткә ия. Гаҗәеп сүз ул. Аны ишеткән кеше, үзеннән-үзе канатланып, синнән алда киенеп машинага чыгып утыра. Өйрәтимме?

Кибеткә икәү барырга кирәк булып, ирем киреләнеп маташса, «Ник мин кирәк инде анда, үзең генә дә барып кайта аласың бит. Минем хәзер хоккей башлана», — дисә, мин һәрвакыт теге тылсымлы сүзне кулланам. Юк, «зинһар өчен» дигән сүз түгел ул. Эшемнән бүленеп, күзләренә туп-туры карыйм да: «Бара алам мин анысы кибеткә үзем генә дә... Ләкин минем өчен ул бер проблема. Йә парковкасы булмый, йә тегесе, йә монысы... Ә янымда син булсаң, барлык проблемалар да юкка чыга. Синең янда мин бернәрсәдән дә курыкмыйм. Синең белән миңа рәхәт», — дим. Ихластан әйтәм. Һәм беләсезме, бармыйм, дип тарткалашкан ирем, мыек астыннан гына елмаеп, киенә башлый. «Әйдә инде, барып кайтсак кайтыйк, только хоккей башланганчы кайтып җитәбез!» — ди. Кайтып җитү-җитмәү — анысы икенче мәсьәлә, ләкин теге сүз чынлап та эшли бит! Кулланып карагыз әле сез дә. Бәлки, кемдер мин белмәгән тагын да тылсымлырак сүзләрне беләдер.

**Лилия ГӘРӘЕВА**, "Сөембикә".

podpiska.pochta.ru

# Әнидән көн саен гафу үтенәм

Тормышта әллә нинди үкенечле вакыйгалар була. Әмма минем кадәр үкенгән кеше бар микән?!

Мин — әти белән әнинең бердәнбер баласы. Әтинең холкы бик начар иде. Аракы белән дус булды. Исереп кайткан чакларында әнигә кул күтәрә торган иде. Бәлки шуңа әни башка бала алып кайтырга уйламагандыр. Әни белән бик интегеп яшәдек без. Әтидән шундый курка идек, ул исереп кайтса, өйдән чыгып качарга тырыштык. Күршеләрдә, туганнарда кунып йөрдек.

Үсмер чакка житкәч, әнине әтидән аерылырга үгетләдем. Әни бу адымга барырга бик курыкты. «Болай яши алмыйм, алайса мин өйдән чыгып китәм», — дигәч кенә ниятләде. Әмма аерылышу тагын бер елга сузылды. Әти әнинең аерылырга биргәнен белгәч, үзгәрде, эчми башлады. Ул ярты ел тормыш гаилә тормышыбызның иң матур чоры булды. Әмма бу бик азга барды, әти кабат үз гадәтенә кайтты. Кабат әнигә шарт куйдым. Әни белән әти аерылышты. Һәм әти безнең тормыштан югалды. Бу да минем катылыгым аркасында. Әтигә безгә килеп, борчып йөрисең икән, полиция чакыртам, дидем. Әти, әллә полициядән курыкты, әллә минән, күренмәде. Без дә аны эзләмәдек. Соңыннан гына туганнары аның үзе кебегрәк хатын белән яшәгәнен әйтте.

Ниһаять, мин әнинең елмайганын күрә башладым. Ул тынычланып китте, хәтта матурайды. Өйдә дә тынычлык иде. Өйгә кайтырга рәхәт. Миңа бу тормыш шундый ошый иде. Әни белән якын дусларга әйләндек. Мәктәпне тәмамлап, университетка укырга кердем. Үскән саен әнинең хатын-кыз икәнен, аңа да ир назы, игътибар кирәклеген аңладым.

Аңа кем беләндер танышырга, аралашырга кирәклеге турында әйтә башладым. Әмма әни ишетергә дә теләмәде. Күрәсең, аның яралары бик тирәндә булгандыр. Ир-ат аның өчен эчү, сугылу, газап белән генә бәйле булгандыр, мөгаен. Бу хакта кабат-кабат сөйләшеп тә, әнине күндерә алмагач, сөйләшү аның өчен газап кына булганын аңлагач, башка сүз кузгатмадым. Без әни белән икәү генә яшәүне дәвам иттек.



Уку йортын тәмамлап, зур компаниянең финанс бүлегенә эшкә урнаштым. Без бернәрсәгә интекмәдек, әни белән ял итәргә йөрдек, фатирны алыштырдык, әмма бәхетнең бер ягы китек кебек иде. Үз халәтемне әнигә сиздерергә теләмәсәм дә, әни күреп-аңлап тора иде. Минем гаилә, яраткан ир-ат турында хыялланганымны аңламый кала алмый иде инде ул. Егетләр белән йөрсәм дә, мөнәсәбәтләребез бервакытта да житдигә күчә алмады. Миңа инде кыйммәтле бүләкләр дә, әллә ни күп игътибар да кирәкми иде. Бары тик яраткан кешемнең кулымнан тотып, янәшә баруын гына тели идем. Әмма тормышта хыялларымны сызып ата торган хәл булды.

Беркөнне эштән кайтканда әнинең күрше ишегалдында утыруын күреп алдым.

— Әни, нишләп утырасың монда, нигә өйгә кермисең? Әллә эштән кайтышлый һава суларга булдыңмы? — дим.

— Мин кайтыр юлны оныттым, кызым...

Башыма китереп суккан кебек булды. Мин әнине кочаклап алдым. Юк, юк, минем әни белән болай булырга тиеш түгел! Аны житәкләп алдым да, шикләремне әнидән генә түгел, үземнән дә яшерергә тырышып өйгә таба атладым.

Икенче көнне мин инде әнине алып медицина үзәгенә киттем. Әнидә Альцгеймер авыруы башланганы ачыкланды. Табиблар билгеләгән даруларны даими эчеп торса, стресс булмаса, авыру көчәймәс дип аңлатты. Әнигә авыруы хакында берни әйтмәдем. Бары тик эштән китәргә күндердем. «Инде үзең өчен яшә, әни, барысы да житә», — дидем.

Әнинең хәле алай ук начар да түгел иде. Вакыт-вакыт кына нидер онытып куя. Әмма аның өчен курыктым, янында һәрвакыт кеше булсын дип, «сиделка» ялладым. Алар дуслашып китте. Минем жаным тынычланды. Әмма әнинең төнлә йокламаулары, кычкырып уянулары бик авыр иде.

Бу хәлләрдән соң ике ай узгач, бер айга стажировка узарга безнең компаниянең чит илдәге филиалына барырга тәкъдим иттеләр. Бик озак уйлангач, тәкъдимне кабул иттем. Алда торган перспективалар да кызыктырды, чит ил күрү

*(Дәвамы 10 нчы биттә)*

podpiska.pochta.ru

*(Башы 9 нчы биттә)*

теләге дә көчле иде, бераз ял итәсем дә килде.

Кайтып әнигә әйткәч, ул бик каты елый башлады. «Кызым, китмә, ялгызымны калдырма», — дип, сабый баладай мине кочаклап алды. Без ул кичне озак кына сөйләштек. Әни минем китүемә күнде. «Бер ай, бары тик, бер ай! Бер ай эчендә берни булмас», — дип уйладым.

Һәм ялгыштым. Кайтып кердем, ә әни мине танымады. Карап торучы хатын мин китеп ике атнадан соң шушындый хәлгә төшкәнен, борчымас өчен хәбәр итмәвен әйтте. Соңгы вакытларда әнинең телефоннан сәеррәк сөйләшкәнен сиздем бит югыйсә...

Әнине кочаклап еладым да еладым. Ә ул миңа аптырап карап торды: «Хәзер әни кайта да, безгә ашарга әзерли, елама», — дип, мине үзенчә юатты. Нинди зур хата эшләгәнемне шунда гына аңладым. Нигә генә әнине калдырып киттем соң?!

Бу хәлләрдән соң күп вакыт үтте. Мин һаман ялгыз. Әйе, компаниянең финанс директоры итеп куйдылар, әмма моңа артык шатланмадым да. Минем өчен бары тик бер генә кеше чын күңелдән сөенә ала. Әмма әни берни аңламый. Эштән әни янына йөгереп диярлек кайтам. Ә ул мине түгел, әнисен көтә. «Мине өемә кайтар», — дип каршы ала. Әнине кочаклыйм да, тынычландырырга тырышам. Дөньядагы иң кадерле кешемне теге вакытта калдырып киткәнемә үз-үземне гафу итә алмыйм. Әнидән һаман гафу сорыйм, әмма ул мине аңламый, бары сабый баладай күзләремә карап утыра.

"Сөембикә".



# Социаль челтәр

Дүшәмбе көннәрендә генә уза торган мәктәп линейкасына бүген көтмәгәндә җыеп алдылар. Мондый гадәттән тыш «линейкалар» йә берәр нәрсә майтарылса, йә үтә дә мөһим чаралар көтелсә генә җыела.

— Хөрмәтле дуслар! Бүгенге линейканы озын-озакка сузмыйбыз. Бер мөһим вакыйганы бөтенегезгә дә җиткерергә булдык, — дип сүз башлады мәктәп завучы Флёра Сәйфетдинова. — Яңа гына өстән фәрман килеп төште. Мәктәп турында район халкына, аннары республикага җиткерер өчен социаль челтәрләрдә эшне көчәйтергә боердылар. Сез социаль челтәр дигән әйберне бездән дә яхшырак беләсез. Һәрберегезнең өендә интернет бар хәзер. «Вконтакте» челтәрендә «Олы Әшнәк урта мәктәбе» дигән төркем ачтык. Хәзер шул төркемгә кешеләр җыярга, мәктәп вакыйгаларын язарга кирәк. Арагызда каләм чарлаучылар бар. Языгыз, кызыклы көннәрегез, дәресләр белән уртаклашыгыз, дус-туганнарыгызны өстәгез. Безнең авылдан каләм әһелләре шактый чыккан, сезнең арада да, бәлки, булачак язучы-журналистлар бардыр. Сез төркемгә күбрәк дуслар өстәгез, мәктәп тормышын яктырткан вакыйгаларны языгыз, мәктәп рейтингын интернет кырларында да үстерик. Конкурс эшләренә бер атна вакыт бирәбез, икенче атнага нәтиҗәләр чыгарылыр. Кем иң яхшы язма теркәп, иң күп лайклар җыя, төркемгә кешеләрне күпләп өсти, шул кешегә махсус бүләк — телефон бирәбез. Телефонны мәктәбебезне тәмамлаган артист Ирек Хафизов үзе тапшырачак. Ул әлеге бәйгенең иганәчесе булып тора. Димәк, киттек, — тырышыгыз, күрсәтегез, языгыз, мәктәп данын бөтен районга, республикага таратыйк, — дип, завуч сүзен тәмамлады.

Мәктәптә конкурслар еш үткәрелә, ләкин монысы укучыларны аеруча да тәэсирләндерде. Бүләккә телефон, диләр ич.

— Егетләр, телефоны нинди, дип сорарга онытканбыз. Андроид микән, гадәти төймәле булмасын тагы, ә бәлки айфон биргәндер әле теге иганәче дигәннәре,— дип класстагыларга сүз катты Айрат.

— Безнең урамга кайта ул Ирек абый, нинди айфон булсын ди анда, үзе дә төймәле телефон белән йөри, — дип көлде Алисә.

— Әйе шул, сорамадык яхшылап. Төймәле генә телефон булса, ул лайклар өчен эшләп тә утырасы юк. Өйдә өч-дүрт телефон бар андый, — дип сүзгә кушылды Ленар. Телефонның нинди икәнлеген белмәсәләр дә, мондый җиңел конкурстан берсе дә читтә калырга ашыкмады. Әнә, шигырьләр язып, иләсләнеп йөрүче Марат шул ук көнне шигырь язып ташлады.

Тау башында горур басып
тора ул безнең мәктәп.
Сүз табалмыйм, остазларны
язарга монда мактап.

Телефонын гел кулында йөрткәч, шунда ук теге төркемгә элеп куйды. Иң беренче булып үз шигыренә лайкны да чәпәде.



podpiska.pochta.ru

– Бу шигырь болай гына, старт бирер өчен генә, соңрак яхшырагын язам әле, – дип, телефонын алып куйды.

Алисә мәктәптә үткән рәсем конкурсы турында мәкалә язарга булган, хәзер рәсемнәрен биргән һәр кешедән, нигә болай ясадың, нигә тегеләй ясадың, дип, интервью алып бимазалый.

Альбинаның узган атнада туган көне иде, әтиләре яңа фотоаппарат бүләк иткәннәр. Ул икенче көнне үк, фотоаппаратын тотып, мәктәпне төрледән-төрле ракурсларда фотога төшереп йөрде: тәрәзәләрне ачып та төшерде, дәрес вакытларында да шыртлатып алды, мәктәп баскычларына ятып та кыланды.

Алмаз исә мәктәпне тәмамлаган кешеләргә интернеттан хатлар язган һәм «Безнекеләр» дигән рубрика булдырып,тегеләрдән истәлекләрен яздырта башлаган. Шул рәвешле, бөтен мәктәп мәш килде. Бер генә конкурста да болай катнашканнары юк иде. Бер атна булып килгәндә, «Олы Әшнәк урта мәктәбе» дигән төркем яңалыклар белән чуарланып бетте, кешеләр артык җыелмаса да, сәгать саен яңалык эленде. Ашханәдәге пешерүчеләрдән рецепт та яздырып куйдылар, завхоз Илдар абыйдан эшенең бик әһәмиятле булуын сөйләттеләр, укытучы Рәсимә апаның ни өчен бер класста ике ел утырып калуын да яздылар... Бу атнада күпләр дәрес әзерләүне дә онытты, телефон отасы килү теләге бөтен мәктәпнең һушын алды. Шәмси генә берни эшләмәде. Беренчедән, аның өендә интернет юк, икенчедән, инде нәрсә язарга да белмәде, чөнки барысын да язып бетерделәр кебек тоелды аңа. Бәйгегә йомгак ясарга бер көн калгач кына, аның башына идеаль фикер килде. Журналист кеше дөресен язарга, ялагайланмаска, дөреслекне фаш итәргә тиеш, диләр бит. Ул да мәктәптәге житешсезлекләрне язарга булды. Күрше егете Айраттан ике сәгатькә кесә телефонын сорады да, төркемгә кереп, алдагы язмаларга үзенчә анализ ясады һәм үзе дә кулына каләм алды.

«Районыбызда әллә ничә Әшнәк бар, ләкин безнеке – Әшнәкләрнең дә Әшнәге.

Авылыбыздан язучылар да, журналистлар да, артистлар да, хәтта тарихчылар да чыккан. Минем дә үткен каләмле журналист буласым килә. Ялагайлыкны җенем сөйми. Менә мәктәптә конкурс игълан иткәннән соң, бөтен укучы мәктәпне мактарга ашыкты. Ни өчен? Телефонлы буласылары килә. Ә болай дөрес түгел ул. Шуңа да мин фаш итәргә булдым мәктәпне.

Мәктәпкә акбурлар кайту белән, биология укытучысы Фәридә апа аларны өенә ташый, чөнки аның кызлары акбур ашарга ярата. Аннары без дәрес вакытында күрше класслардан акбур сорап интегәбез. Ел башында мәктәпнең бөтен укытучыларына да ноутбук бирделәр, ә информатика укытучысы алар белән бергә булган флешкаларны алып калган да хәзер шуларны «авито»да сатып ята (миңа моны ышанычлы чыганаклардан җиткерделәр). Авылыбыз мулласының алты баласы бар, аларның берсе дә ашханә өчен түләми, имеш, әтиләре мулла, сәдакага гына яшиләр. Өйләренә беркөнне кергән идем, аларның өй түрләрендә «ЖК» телевизор, күн диван, массаж ясый торган кресло, тагы әллә ниләр бар. Ә балалары мәктәптә бушка ашый. Ник мәктәп җитәкчелеге аларны барып тикшерми? Укучылар бөтенесе дә бертигез булырга тиеш. Узган язда мәктәпнең түбәсен яңа калай белән яптылар, завхоз Илдар абый тәки чәлдерде калайларның бер өлешен. Оялмыйча да үзләренең түбәләрен шул калай белән ябып куйды. Бөтен авыл күрә моны, мәктәп һәм Илдар абыйларның түбәләре генә шул зәңгәр төстә бит. Тик берсе дә дәшми.

Шундый хәлләрне саный китсәң, бик күп алар бездә. Бездә генә түгел, һәр мәктәптә дә бар алар. Күрә белергә, фаш итәргә генә кирәк намуссыз кешеләрне. Батыр йөрәкле егет булып, каләм белән көрәшүдән дә яхшырак эш юктыр».

Менә иртәгә конкурска нәтиҗә ясалыр, бүләкне дә лаеклы кешегә бирмәячәкләр. Әти-әниләре кибет тотучы Алисәгә эләгер инде, йә булмаса ай саен телефонын алмаштыручы Фидаильгә, дип уйлады Шәмси һәм, «бисмилласын» әйтеп, үзенең уникаль язмасын стенага беркетеп куйды.

Шәмсинең язмасы төнге унбердә генә беркетелгән булса да, иртәнге сигезгә Әшнәк мәктәбе төркеменә 500дән артык кеше өстәлгән (авылда да аның кадәр хуҗалык юк бит хәтта), 80 лайк куелган, 15 репост ясалган иде. Хәбәр тиз арада директорга килеп җитте, директор, язманы күрү белән, үзенең сәркатибе Ләйсәнгә комментарийларны алып ташларга, язманы тизрәк юкка чыгарырга кушты.

Математика дәресе вакытында Шәмсине директорга чакыртып алдылар, ул инде төнлә нәрсә язганын үзе дә анык кына хәтерләми иде. Директорның кара йөзен күрүгә, барысы да тиз исенә төште үзе.

– Энем, син үзеңне кем дип белдең шуның кадәр?! Башкалар арасыннан шулай аерылып торырга яратасың инде, ләкин бу эшең бернинди кысаларга да сыймый. Бүген төштән соң әти-әниеңне көтәбез.

– Фәрит Хәмитович, конкурска линейкада йомгак ясарга вәгъдә иткән идек. Ирек шалтыратып, кайта алмавы турында әйтеп гафу үтенде, телефонны үзегез генә тапшырыгыз инде, диде. Нишлибез? – дип, ишектән сәркатип Ләйсән килеп керде.

– Беренчедән, төркемне чистартыгыз, комментарийларны админ аша гына язып була торган итеп ясагыз! Ә бәйгегә йомгакны хәзер ясыйбыз. Менә шушында. Бәласеннән башаяк. Ни дисәң дә, бер төндә 500 кешене җыйган бит. Молодец, Шәмси! Менә сиңа телефон! Шуның белән, энем, сөйләшүем тәмам, калганын әтиең аша аңлатырмын, безнең телне аңламыйсың син барыбер, – дип, директор, ишеген ачып, Шәмсине чыгарып җибәрде.

Шәмси, кулына чыбыклы телефонын тотып (әларның өйләренә телефон да кермәгән бит), «эх, башта нинди телефон икәнен төпченәсе калган, юкка төн йокыларымны калдырып язып ятканмын» дип уйлап чыгып китте.


Мәктәпкә эшкә йөргән кебек еш барырга күнеккән әнисе урынына бүген кичкырын гына Шәмсинең әтисе китте.

**Алинә БИКМУЛЛИНА,**

"КУ".

podpiska.pochta.ru

Булмас димә!



# “Килешенгән бәя шул ук калачак”: “Коръән ашы”нда күргәннәрем

Мин бу язмамда беркемне дә хурларга да, мактарга да җыенмыйм. Нәрсә күрдем һәм ничек күрдем шулай язам. Шамкай әйтмешли, күпмегә алдым, шундый ук бәягә сатам. Геройларымның исемнәре дә билгеле сәбәпләр аркасында үзгәртелеп бирелер.

Татарстанның төньяк районына Коръән ашына чакырулы идем. Алдан ук белеп бардым, хатыннар мәҗлесе булачак. Исән-имин килеп җитеп, чакырган хуҗалар белән хәл-әхвәл белешкән арада, мәҗлескә чакырулы апалар да җыела башлады.

Менә йорт хуҗасы абыстайны машинага утыртып алып килде. Абыстай өйгә кергәч: “Нихәлләр?!” (Әссәламүгаләйкүм түгел!) — дип көр тавышы белән гөргелдәп куйды.

Вәгазь темасы итеп кыямәт, сират күперен үтү алынган иде. Без ир-атлар икенче бүлмәдән бу кызыклы теманың берәр сүзен төшереп калдыра күрмик дип колакларыбызны булдыра алганча шомрайтып, йотлыгып тыңлый башладык.

Иң беренче эш итеп вәгазьчебез апаларга кабердә биреләчәк сорауларга җавапларны ятларга кушты. Аннан мәхшәр мәйданында сорау алу моментларына тукталып та тормыйча, сәяхәтебезне сират күперенә дәвам иттек.

Абыстай:

— Сират күперен исән-имин чыгар өчен, ул кылдан нечкә күпердә аякларның таймавы мөһим. Моның өчен бер сикритне онытмагыз, тәһарәт алганда да, мунчада юынганда да аякларыгызны сабын белән юарга ярамый, чөнки сабынлы аяк сират күперендә таячак икән (имәндә икән чикләвек! Сират күперендә таймас өчен Аллаһның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәп, Раббыбызның шәфкатенә ирешергә кирәк дип ничә еллар адашулы фикердә булганмын бит. Намаз да укыма, ураза да тотма... иң мөһиме — аягыңны сабынлап юма!). Унбиш минутлап ничек Аллаһны алдап җәннәтле булу турында сөйләгәч, эшемне кырган канәгать тавыш белән:

— Альхамдыриллах, вагаз бетте, — дип гөргелдәп куйды абыстай.

Мин әкрен генә хуҗабикәне ымлап чакырдым да, апалар арасында утыручы югары дини белемле, алты елдан бирле дини гыйлем бирүче Җәмилә остаздан Коръән укытуын үтендем. Хуҗабикә табынга кереп, остабикәдән Җәмилә остаз Коръән укыса каршы килмисезме дип сорады.

Остабикә:

— Астагарифулла (әстәгъфируллаһ диюедер инде), бу нинди оятсызлык, миннән узып беркем дә Көрән (әйе, нәкъ шулай әйтте) укымаячак.

Хуҗабикә миңа мөрәҗәгать итеп:

— Хәзрәт, табында берничә Коръән укучы булган очракта кем укырга тиеш?

— Тәҗвид кагыйдәсен белгән һәм махраҗларны дөрес чыгарып Коръәнне җиренә җиткереп укучы, — дип җавапладым.

Абыстай:

— Ярар, алайсак, укысын, Гөлфия (хуҗабикә), Коръәнне кем укуына карамастан, килешенгән бәя шул ук калачак.

Җәмилә остаз, “Йәсин”, “Тәбарәк” сүрәләрен укып бетергәч, дога кылу өчен “сүз дилбегәсе”н үз кулына алды остабикәбез. “Йә, Раббым, безнең күнелләрне үзеңнең динеңә беркет”, — дигән доганы гарәпчә укыды.

«Йә мукъаллибә-л-къулүби, сәббит къальби галә диниик!» Табын артында утыручылар кычкырып “әәмиин” дип тордылар. Ләкин абыстай “Къальб” (Йөрәк, күңел) диясе урынга Кәлб (эт) дип кылды бит доганы. “Безнең этләребезне үзеңнең динеңә беркет!” дип дога кылды, аңа әәмиин дип тордылар. Мәҗлес тәмамланды. Без дә юлга кузгалдык.

Тик күңелгә нәрсәдер тынгылык бирмәде. Мәҗлесне анализ ясап кайттым (вакыт күп, 4-5 сәгать кайтасы). Бар да гадәттәгечә кебек.

Ниһаять күңелемә тынгы бирмәгән нәрсәне дә таптым кебек. Мәҗлес ахырында абыстай дога кылганда:

— Йа, Раббым, борын аслары да кипмәгән белдеклеләрдән мине ерак кыл, — диюе сәбәпче икән бит.

Мөхәммәд (с.г.с.)нең “Күңелендә тузан бөртеге кадәр генә тәкәбберлек булган кеше җәннәтнең исен дә татымас”, — дигән хәдисен онытмасак иде, дусларым!

Онытмыйк, Ислам дине кәсеп чыганагы түгел, ул безнең яшәү рәвешебезгә әйләнсен иде.

**Мөхәммәд САДЫЙКОВ,**
**Чистай.** «ШК».

podpiska.pochta.ru

# Эше булмаган яки эшен югалткан затлар эшсезлек буенча пособие алырга хокуклы

Эшсезлек буенча пособие күләме 2023 елда да үзгәрмәде. Ул узган елдагыча, ягъни 12 792 сум тәшкил итә. Бу максималь күләме, ә минималь пособие 1 500 сум.

Аңа кемнәр хокуклы? Ә кемнәр мәхрүм? Россиядә яшәүче чит ил гражданнары эшсез калгач, әлеге пособиегә дәгъва кыла аламы? Пенсиягә чыгар алдыннан эшен югалткан кешеләргә дә ул түләнәме?

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге белән берлектә әлеге сорауларга җаваплар тәгаенләдек.

**Кемнәргә бирелми?**

Пособие алу өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә мөрәҗәгать итәргә һәм эшсез буларак исәпкә басарга кирәк.

Тик бөтен кеше дә моннан файдалана алмый.

Пособиедән мәхрүм булганнар исемлеге:

— 16 яшьтән яшьрәкләр;

- картлык яки тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алучылар;
- ирегеннән мәхрүм ителү урыннарында яки төзәтү эшләрендә булучылар;
- хезмәт килешүе нигезендә эшләүчеләр;
- килешү нигезендә продукция сатучылар яки түләүле эш башкаручылар;
- шәхси эшкуар, нотариус, адвокат яки үзен үзе эш белән тәэмин итүчеләр;
- хәрби, альтернатив гражданлык хезмәтен үтәүчеләр яки бүтән органнарда хезмәт итүчеләр;
- көндезге бүлектә укучылар;
- ярдәмче кәсепләрдә мәшгульләр, крестьян-фермерлык хуҗалыклары, җитештерүчән кооперативлар, артель әгъзалары;
- коммерцияле оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар).

**Исәпкә басар өчен нишләргә?**

Гражданнарны рәсми рәвештә эшсез дип, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге таный һәм эшсезлек пособиесенең күләмен дә ул билгели.

Моның өчен даими теркәлү урыны буенча мәшгульлек үзәгенә турыдан-туры да мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Әгәр дә даими теркәлү урыны буенча яшәмисез икән, борчылырга кирәкми, чөнки тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә “Россия эше” порталы аша да теләгән кеше дистанцион һәм онлайн режимда гариза бирә ала. Ләкин шуны да истә тоту кирәк, күрсәтелгән барлык мәгълүматлар да тикшереләчәк. Әгәр дә мәгълүматлар ялган яки дөрес түгел икән, гариза бирүчене җаваплылыкка тартырга мөмкиннәр.

## Моны белү файдалы



**Пособиегә кемнәр хокуклы? Күләме?**

Төрле сәбәпләр белән эшсез калучыларга пособие күләме гражданнарның соңгы эш урынындагы уртача эш хакыннан чыгып билгеләнә. Иң төп шартыы: хезмәт килешүе буенча эшләгән кеше мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткәнче бер ел эчендә эштән киткән һәм бу чорда эшләгән көннәре 26 атнадан да ким булмаска тиеш.

Беренче өч айда ул уртача хезмәт хакының 75 процентын тәшкил итә, ләкин 12 792 сумнан артмый, ә шуннан соңгы өч ай дәвамында пособие күләме уртача хезмәт хакының 60 процентына тәңгәлләшә, тик 5 000 сум чиген узмый. Гамәлдәге кануннарда әнә шундый шарт бар — эшсезлек буенча пособиенең тәгаенләнгән максималь һәм минималь күләме саклана.

Ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, әлеге категориягә балалар арасыннан беренче тапкыр эш эзләүче (элек эшләмәгән) һәм мәшгульлек хезмәте органнары тарафыннан беренче тапкыр эшсез дип танылган затларга эшсез дип теркәлгән көненнән алып 6 ай дәвамында, теркәлү көнендә Россия субъектында уртача айлык хезмәт хакы күпме исәпләнсә шул күләмдә түләнә. Эшсезләр исәбенә теркәлгәннән соң 6 ай үткәч, шулай ук бу чорда 23 яшь тулса эшсезлек пособиесенең минималь (район коэффициентларын куланып) күләме билгеләнә.

**Пенсия алды яшендәгеләргә тиешме?**

Пенсия алды яшендәге затлар да әлеге пособиедән мәхрүм түгел. Алар теләсә нинди сәбәп белән эштән киткән очракта (берничә искәрмә бар) бер ел эчендә эшләгән көннәре 26 атнадан да ким түгел икән, шулай ук эшсезлек пособиесенә дәгъва кыла ала. 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы мәшгульлек турындагы канунда башкасы каралмаган булса, район коэффициенты күләмендә арттырылган

*(Дәвамы 14 нче биттә)*



podpiska.pochta.ru

*(Башы 13 нче биттә)* эшсезлек буенча пособиенең минималь күләме тиеш – 1500 сум.

**Пособиенең иң түбән күләме кемнәргә билгеләнә?**

- Беренче мәртәбә эш эзләүчеләр(элек эшләмәгәннәр);
- озак (1 елдан артык) тәнәфестән соң хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә теләүчеләр;
- Россия кануннарындагы тәртиптә шәхси эшмәкәрлек эшчәнлеген туктатучылар;
- хезмәт дициплинасын бозган яки башка гаепле гамәлләр өчен эштән куылучылар;
- эшсез калганчы ел дәвамында 26 атнадан ким эшләмәүчеләр;
- мәшгульлек хезмәте органнары тарафыннан укуга җибәрелеп һәм гаепле гамәлләре өчен куып чыгарылучылар;
- крестьян-фермерлык хуҗалыгы әгъзасы булудан баш тартучылар;
- соңгы эш урыныннан ахыргы 3 айда уртача хезмәт хакы турында белешмә тапшырмаган затлар.

**Чил ил гражданнарына түләнәме?**

Гамәлдәге кануннарда Россия территориясендә яшәүче чит ил гражданнарына эшсезлек буенча пособие түләү каралмаган. Алар дәүләт ярдәменнән башка да үзләрен һәм гаиләләрен яшәү минимумыннан түбәнрәк булмаган дәрәҗәдә тәэмин итәргә тиешләр. Юкса, эшсез дип танылып, Россиядә өч ел дәвамында эшләр һәм яшәр өчен бирелгән рөхсәттән (РВП) һәм Россия гражданы булмаган килеш ил территориясендә озак вакыт яшәү хокукыннан (ВНЖ) мәхрүм калырга мөмкиннәр.

**Гөлнур ШӘРӘФИЕВА әзерләде.**

# Ирләргә җенси көчсезлектән ничек котылырга?

*Җенси көчсезлек... Моның белән очрашмаган бер генә ир дә юктыр. Табибларның күзәтүләре дә сискәндерә. 30-35 яшьлек ирләрнең өчтән бер өлешен җенси көйсезлек борчый икән. Ләкин иң гаҗәбе, ирләрнең күбесе әллә үз хәлен аңлап җиткерми, әллә сәбәпне башкадан эзли, никтер үгет-нәсыйхәттән өстен калырга тели. Тикшеренергә ашыкмаучылар өчен көч бирүче берничә дәвалану ысулы тәкъдим итәбез.*



*Узган ел кабак уңышы мул булды. Күпләребезнең әле дә узган елгы кабагы бар. Нишләтергә дип баш ватасы да түгел, дәвалану өчен чи килеш ашарга яисә согын сыгып эчәргә кирәк. Ирләрдә җенси көчне арттыру өчен ул бер дигән ризык!*

*Беренче атнада көнгә бер тапкыр 20-30 грамм, икенче һәм өченче атнада көненә икешәр тапкыр 100әр грамм, дүртенче атнада исә көненә өч мәртәбә 100әр грамм ашыйлар. Алга таба да кабакны рационнан алып ташлыйсы түгел! Кабак белән туклануны дәвам итеп, 4 атна буена көненә 3әр тапкыр 150 шәр грамм ашагач кына, ике атна тәнәфес ясыйсы. Аннары дәвалануны кабатларга кирәк. Тик бер шарт үтисе: чи кабакны ризыкка кадәр 20 минут алдан ашап кую хәерле.*

*Кабак суын эчеп дәвалану тәртибе болайрак. Яңа гына сыктырылган кабак согын беренче атнада көненә бер тапкыр яртышар стакан гына эчәргә кирәк, артыгы ярамый. Икенче атнада көненә ике тапкыр яртышар, ә өченче атнада көненә ике тапкыр берәр стакан эчелә. Дүртенче атнада норма күбәя – көнгә 3 тапкыр берәр стакан кабул итәсе. Туктамыйбыз, алга таба дүрт атна дәвамында көн саен 3әр стакан кабак суы эчәсе әле. Ике атна ял иткәч, дәвалануны кабатларга киңәш итәбез.*

*Болай дәвалану беренче карашка бик мәшәкатьле кебек. Әмма авыру тагын да хәтәррәк. Ләкин кабак суы бөтен кешегә дә ярамый, шуңа да сак булыгыз, алдан табиб белән киңәшсәгез дә зыян итмәс. Чөнки, ашказаны, шикәр авыруларыннан интеккән кешеләргә кабакны чи килеш ашарга рөхсәт ителми.*

*Мондый чирләрдән интегүчеләр күңелсезләнмәсен, дәвалануның башка ысулларын да тәкъдим итәбез.*

*Бака яфрагының орлыгы да җенси көчсезлектән бик әйбәт булыша икән. Күләгәдә киптерелгән орлыкны бер аш кашыгы күләмендә бер стакан кайнап чыккан суга салып, әкрен утта 5 минут кына кайнатасы. Артыгын тотмагыз. Суынгач сөзәргә дә, көнгә 4 мәртәбә икешәр аш кашыгы эчәргә. Дәвалану вакыты – 4-6 ай.*

*200 грамм коньякка 3 лимонның суын сыгып, шуңа 3 чи йомырка сарысы өстәргә һәм бик әйбәтләп болгатырга кирәк. Шуны ашарга 20 минут кала көненә 3 тапкыр берәр аш кашыгы йотып җибәрергә.*

*Халык табибларына кушылып, безнең дә үз киңәшебезне бирәсе килә. Соңгы елларда яшьләр кыска куртка, кышын да балагы кыска чалбар кия. Аңлашыла да – заман модасы. Ләкин бу мәни бизенең ялкынсынуына китерүче төп сәбәпләрнең берсе. Салкын тидерүе тиз, ә менә вакытында дәваланмау, берничә елдан җенси яктан көчсез хәлгә төшерә. Аң булыгыз, егетләр!*

*Иң мөһиме – алдан табиб белән киңәшегез!*



podpiska.pochta.ru

# Беренче югалту

Егет кызны мәңгегә яратырмын дип уйлады. Язның бер көнендә булган вакыйга чибәркәйне йөрәгеннән мәңгегә сызып ташларга мәҗбүр итте.

Алар кышның бер матур көнендә танышкан иде. Бөтен дөнья ап-ак кар белән капланган, суык җил агачларны җанландыра. Илназ дус егетләре белән шундый матур кичләрдә күрше авылга кичке уеннарга бара торган иде. Һәм шунда ул Гүзәл белән танышты. Кичке уенда кыз башта күренмәде, соңрак исә ул дус кызлары белән килеп чыкты. Бөтен егетләрнең күзе бу кызга төште, чөнки әле аны авылда беренче тапкыр күрүләре. Гүзәл шәһәрдә тора, ә авылга әби-бабасы янына кайта ул. Гүзәлне күрүгә Илназ аңа гашыйк булды. Гүзәл дә битараф калмады. Шул көннән соң егет бу авылга көн дә килеп йөри башлады. Урамда Гүзәлне күрүгә, аның йөрәге дөп-дөп тибә, сулышы әллә нишли, әйтәсе сүзләрен оныта, сөйләшкәндә каушый. Бераз оялчанрак егет ул Илназ. Күп сөйләшми, күп сөйләшкәнне дә яратмый, үзе исә бик тырыш, укуда да, спортта да сынатмый, укуы яхшы булгач, сыйныфташларына да булыша, җитез, акыллы, көчле, кыскасы, бар яктан да килгән. Ә менә кызны күрүгә әллә ничек югалып кала. Буш вакытында шигырьләр укырга, җырларга ярата. Урамда баян уйнап, башкаларны җырлата, кайвакыт үзе дә шигырьләр, җырлар иҗат итә.

Гүзәлгә мәхәббәте турында ничек әйтергә дип баш ватып йөри торгач, ниһаять, ул аңа хат язды: «Кадерле Гүзәл! Синең кебек кешене беркайчан күргәнем юк иде. Сине күрүгә, кәефләрем күтәрелә. Бер күрүдә сиңа гашыйк булдым, гашыйк булып яшим әле дә. Елмаюыңны күрүгә, бөтен күңелсезлекләр юкка чыга, күңелләр эреп китә. Сине очратканнан бирле бүтән бер кызга да күтәрелеп карыйсы килми. Яратам мин сине!» Бу сүзләрне укыгач, Гүзәлнең шатлыгы эченә сыймады, чөнки әле аңарга болай мәхәббәт аңлатучы юк иде. Аннан соң бу хатның кулдан язылуы да кызга бик ошады.

Шулвакыт кайдандыр Илназ үзе килеп чыкты. Аның кулында баян иде һәм ул Гүзәлгә багышлап бер җыр җырлады. Кыз сүзсез калды. Шушы көннән башлап алар гел бергә булдылар. Илназ көн саен Гүзәл янына килә һәм алар төнгә чаклы бергә кичке урамнар буйлап йөриләр. Бу матур парга хәтта күктәге йолдызлар белән ай да көнләшеп карыйдыр кебек. Хәер, көнләшүчеләр җирдә дә күп була.

Көннәрдән бер көнне Илназның иң якын дусты Идрис армиягә алынды. Аны бик матур итеп озатып җибәрделәр. Ике айдан соң Илназга да армиягә китәргә дигән хәбәр килеп төште. Аны озату кичәсе дә бик күңелле үтте. Гүзәл аны көтәргә дип сүз бирде. Шулай бер-бер артлы җәй, көз һәм кыш узды. Гүзәл белән Илназ гел хат алышып тордылар. Хатлар аша Илназ Гүзәлгә багышланган шигырьләрен дә җибәрә иде. Атнага бер тапкыр телефоннан да сөйләшеп алалар. Тик... хат алышулар кинәт туктады да куйды. Илназның кайтуына инде бер ай гына калганда бу. Кызның телефоны да «дәшми». Менә Илназ, солдат хезмәтен тутырып, туган ягына кайтып төште. Аны бик күп дуслары, танышлары, тугантумачалары каршы алды. Болар арасында Гүзәл дә бар иде. Ләкин ул бик коры сөйләште.

Берничә көннән соң Илназ Гүзәл кунакка кайта торган авылга барды һәм кызны дусты Идрис белән күрде. Идрис Илназга караганда бер айга иртәрәк кайтып, Гүзәлне үзенә каратырга да өлгергән икән бит! Илназ егылыплар китә язды. Шул көнне ул иң якын дустын һәм сөйгән кызын – икесен берьюлы! – йөрәгеннән мәңгегә сызып ташларга мәҗбүр булды.

**Илзирә СӘЛӘХОВА,** «КУ».



## Гомер буе кешедән качып очраштык

Мине бер сорау борчый. Бәлки сез бу сорауга җавап бирерсез. Әйтегез әле, ярату – гөнаһмы ул? Кешегә гашыйк булып, аны яратып яшәү начар гамәлме?

Ләйсән белән бергә үстек, бер сыйныфта укыдык. Әниләр дә дуслар булып аралашып яшәде. Ләйсәннең бездән ике яшькә кечерәк бертуган энесе бар. Исемен Ленар дип әйтик. Кайвакыт ул да безнең белән урамга чыга, клубларга йөри иде. Безнең арадагы мәхәббәт хисләре үсмер чорда кабынды бугай. Ләкин бу хакта һичкем белмәде, сиздермәдек. Гомер буе кешедән качып очраштык. Ни өчен икәнен үзем дә белмим. Бәлки әниләрдән курыкканбыздыр, бәлки Ләйсәннән... Ни дисәң дә, ул Ләйсәнгә генә түгел, миңа да энем кебек иде.

Бервакыт әниләре Ленарны бер кыз белән таныштырды. Ул чакта аңа 18 яшьләр булгандыр. Әти-әни сүзеннән чыкмый торган егет теге кыз белән очраша башлады. Аның аркасында без хәтта сөйләшмичә йөрдек. Ленарга үпкәм зур иде. Мин дә бер егет белән таныштым. Тик йөрәгем Ленарны сагынып елады. Егетем белән озак очраша алмадык, араларны өздек. Ә Ленар теге кызга өйләнде, кызлары туды...

Гаилә дуслары булгач, Ленарның әниләре бәйрәмнәргә безне дә чакыра. Гадәттә, әни үзе генә бара иде, ә бервакыт мин дә аңа ияреп барырга булдым. Һәм шунда без Ленар белән күрештек. Күрештек тә, мәхәббәтебез кабат уянды. Беренче мәхәббәт. Ул хисләр беркая да китмәгән, бары күңелнең бер почмагында сакланган булган икән.

Ленар белән очраша башладык. Теге вакыттагы кебек кешедән качып-посып. Әмма бу юлы күңелдә бөтенләй башка курку. Без инде 30 яшькә якынлашып киләбез. Ленар гаиләсен ташлап китмәячәк. Мин дә баласының ятим үсүен теләмим. Шул ук вакытта тормышымны аннан башка күз алдына китерә алмыйм. Ул да, мин дә бер-беребезне үлеп яратабыз. Никләр генә теге чакта кавышмадык икән?

Инде безгә нишләргә? Гомерем Ленарны яратып, аның белән очрашуларга тилмереп яшәп ялгызлыкта узармы? Минем дә парлы буласым, бала табып тулы гаиләдә яшисем килә.

**Илсинә,** «ШК».

podpiska.pochta.ru

# Китми тор әле



Ишек бусагасын атлап кергән хатын ут яндырырга өлгермәде, аяк астын абайламыйча, нәрсәгәдер абынып барып төшә язды. Ныклабрак караса, бу иренең зур юл сумкасы булып чыкты. “Нәрсә эшли ул монда, нишләмәкче була, кая җыенган бу?” — башында килеп туган шундый сорауларга җавап таба алмаган хатын озакка сузмыйча кемгәдер чылтырата башлады:

— Нишләргә дә белмим, юк, әле ачып карамадым, кая җыенганын кем белгән аның. Әһә, монда төсе уңган өч футболка ята, иске ике күлмәк һәм алмашка кия торган чалбары бар. Туктале, тукта, әстәгъфирулла, хәтта кышкы бүрегенә кадәр монда түгелме? Анлашылмый, җәй уртасында бүрек киеп кая бармакчы буладыр? Элеккеге берәр җанашына җыенган дисәң, тугызынчы класста үбешеп йөргән аларның берсе күптән кияүдә инде. Икенчесе янына җилкәсе сүтелгән футболка киеп барып булмастыр шул, ул хатын турында тәмам баеп беткән дигән сүзләр йөри. Хәзер аның янына кыйбатлы иномаркада килеп туктасаң да, минем мәхлуккә борылып карамаячак. Башыма ябышты, нишләргә җыенгандыр бу хыялый.

И-и, дустым, элек аңа эш таба алмыйча интекканәмне беләсәң иде. Якын танышларым аша гына тимер-томыр складына көч-хәл белән урнаштыра алдым. Нишләп ул складка дисеңме? Беренчедән, анда хатын-кызның әзе дә юк, шуңа борчылырга кирәкми. Тагын шунысы да бар, ул складта урланасы күптән урланган, утыртырлар дип куркасы юк. Әллә мин әйтәм, шундый яхшы эшне ташлап, берәр кая китәргә йөриме бу сантый? Ышан аңа, кеше сүзен тыңлап ияреп китүе дә бар.

Минемчә, ул ирләргә беркайчан ышанырга ярамый, янында вакытта да аларга һәрвакыт күз-колак булып торырга кирәк. Ерак барасы юк, бер танышымның ире читкә акча эшләргә чыгып киткәч, шундагы бер хатын белән яши башлаган. Икенче танышымныкы киткән җирендә өйләнмәгән анысы, әмма яшь хатынын үзе белән ияртеп кенә кайткан. Аны күрүгә мондагысы: “Нишлисең, оятсыз, мин бит синең законлы хатының!” — дип кычкыргач: “Күңелемә ятышлысын шулай эзләп тапканым өчен гафу ит”, — дип, авыз ерып тора ди. Инде нәрсә уйларга да белмим, дустым, әллә минеке дә кешедән күреп, кая да булса да китеп, машиналык акча эшләмәкче буламы? Миннән шулай җиңел генә котылмакчы бугай, китәрмен мин аңа, әле белгән юк, кем җибәрергә җыенадыр аны.

Шулвакыт ишектән кулына бер пакет сосиска тоткан ире килеп керде:

— Карале, матурым, әйтергә онытканмын, безнең эштә берәү еракка барып күп итеп акча эшләргә исәпләп тора. Минем дә яңа машинада йөрисем килә, шуңа аңа ияреп китәргә булдым. Бу сосисканың самолетта тамак ялгарга кирәге чыгар дип уйлыйм, бик озак очасы диләр. Йә, ничек, акча эшләргә шунда китеп барсам, син ризамы?

Моны ишетүгә хатынының чырае аз гына да үзгәрмәде. Күрәсең ул бу хәбәргә күптән әзер иде.

— Борчылма, оча калсаң, ач калмассың. Тик син каядыр китү турында хыялланма. Нәрсә, минем белән яшәү туйдырдымы? Тынычлан, балыкка йөрергә тотылган иномарканы үзем дә алып бирә алам мин аны. Уйлап кара әле, кемгә кирәгең бар синең анда? Анда берәр хәйләкәр хатын кулына эләгеп, бөтен эшләгәнең аның кесәсенә кереп барачагы турында да онытма. Күгәргән тимер-томыр складында акчаны күп тамызмасалар да, тамагың тук, өс-башың бөтен булды, янадан-яңаны алып тордым, нәрсә җитми сиңа тагын?

Ирнең башын тирән уй басты. Аның нидер турында ныклап уйлый башлаганы йөзенә чыккан иде.

— Нәрсә, ялгыш ишетәмме, машинаны үзем дә алып бирәм дисеңме? Бераз тотылганын күптән күзаллап куйган идем. Болай булгач, белмим, синең яныңнан нәрсәгә каядыр китәргә җыенамдыр. Акчага кызыгып күпләр китеп карады, аннан баеп кайткан берәүне дә очратканым юк әле. Бер уйласаң, мондагы тормыш та начар түгел, эшләгән кешегә эш муеннан. Әнә, авылга кайтып әниеңнең егерме биш сутый бәрәңге җирен утап чыгасы бар, малына печән чабып куйсаң да зыян итмәс, мунчага утын да әзерлисе булыр. Әбиемне яратам мин аны. Күпләр җәйге ялларын чит илдә уздырырга тырыша, ә миңа монда да начар түгел. Син янымда булганда барысына да риза. Менә җиләр, бәхет аяк астында булганда, каядыр китәргә җыенам тагын...

**Илдар ХӘЙРУЛЛИН.**

podpiska.pochta.ru

**Баш мөхәррир:**
**Мәхмүтева Гүзәл Раузит кызы**

***Тел.: 89631392376;***
***Хатлар бүлеге:***
***8(843) 523-45-31.***
*Эл. почта: seberke@mail.ru*

**Редакция һәм нәшрият адресы: 420100, Казан шәһәре, Академик Глушко урамы, 8 йорт, 280 бүлмә (баш офис); 420100, Казан, Бондаренко урамы 24 йорт, 77 бүлмә (кече офис).**

Гамәлгә куючы: Гүзәл Рәүзит кызы Мәхмүтева
Нәшер итүче: ИП Махмутова Г.Р.
Газета 2017 елның 26 декабрендә Роскомнадзор идарәсе тарафыннан теркәлде.
Теркәү таныклыгы Пи№ФС77-71996
Татарстан каталогындагы индексы - П 5250.
АДРЕС: г.Казань ул. Ак. Глушко, д. 8-280
ОГРНИП 311169021700152 ОТ 05.08.2011г.
ИНН 165122333656
р/сч. 40802810262000010191
в ПАО «Сбербанк России»
кор/сч. 30101810300000000603
БИК 049205603
Махмутова Гузель Раузитовна.

Газетадагы язмаларның эчтәлеге өчен авторлар үзләре җаваплы.
Язмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Газетадан язмаларны күчереп бастырганда рәсми рөхсәт булу сорала.
«Манзара» нәшрият-полиграфия комплексында басылды.
(Казан шәһәре, Бондаренко урамы, 24 йорт, 77 бүлмә.)
Газетага тираж сертификаты бирелгән.
Кәгазь форматы А4, күләме 2 басма табак.
Газетаның басылып чыгу вакыты: 09.02.2023 ел, 8.00 сәг.

4 623721 598128

Заказ № 1648
Гомуми тираж 1200
Сату бәясе ирекле.